ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2022 г. Заинск № 13

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2022 елның 02 февраленнән Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6964,68 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карар 2022 елның 2 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2021 елның февралендагы 6 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Р. Садртдинов**

ТР Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре башкарма комитетының
2022 елның «____» ___________
___ номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 02 февраленнән
Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә мәет җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең
бәяләре

| Хезмәт күрсәтүләрнең исеме | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 649,00 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 132,25 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 183,43 |
| Барысы | 6 964,68 |

ТР Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре башкарма комитетының
2022 елның «____» ___________
___ номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 02 февраленнән
Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә мәет җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең
бәяләре

| Хезмәт күрсәтүләрнең исеме | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 726,37 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1976,90 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1105,18 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3156,23 |
| Барысы | 6 964,68 |